**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**СТАРОМЕНЗЕЛЯБАШСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**САРМАНОВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ МИНЗӘЛӘБАШ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

---

РЕШЕНИЕ
2020 елның 29 сентябре

КАРАР
№ 5

Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының "Иске Минзәләбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бердәм шәхси башкарма орган буларак яллаучы (эш бирүче) вәкиленә коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә катнашу яисә аларның коллегиаль органнары составына керү өчен кире кайтарылмый торган нигездә катнашу өчен рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 29 августындагы 18 номерлы карарын гамәлдән чыгару турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясындагы 1 өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Гамәлдән чыгарырга:

Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Иске Минзәләбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең бердәм шәхси башкарма орган буларак идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) яисә аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керүе

өчен кире кайтарылмый торган нигездә катнашу рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 29 августындагы 18 номерлы карарны.

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл жирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Минзәләбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрне коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) идарәсендә шәхси бердәм башкарма орган сыйфатында кире кайтарылмый торган нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Иске Минзәләбаш авыл жирлеге Советының 2019 елның 29 апрелендәге 10 номерлы карарына үзгәреш кертү турында» карарны.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO TATARSTAN.RU) һәм «Интернет»мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Шарләрәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башкарма комитеты житәкчесенә йөкләргә.

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Советы Рәисе А.Н.Габдрахманов